*Ильһам Фаил улы Фәттахов,*

*филология фәннәре кандидаты,*

*Казан федераль университеты доценты*

# Асылыбызга кайту

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәлгаакыйбәтү лил-мүттәкыйн. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһии вә сахбиһии әҗмәгиин. Әссәләәмүгаләйкүм вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтүһ!

Кабан күленең яр буенда искиткеч гүзәл манаралы мәчет бар. “Ислам динен кабул итүгә 1000 ел тулу хөрмәтенә салынган бу мәчетнең язмышы гаять гыйбрәтле. Архитекторы – инженер Печников. Мәчет 1914 елда янәшәсендәге мәдрәсә бинасы белән бергә салына башлый. Ни хикмәттер, татар берәр бәрәкәтле эшкә дәррәү кубып тотынса, аның бу гамәлен сугыш бүлдерә дә куя. Беренче бөтендөнья сугышы купкач, мәчет төзелеше дә туктатыла. Әмма куелган максат милләт йөрәгендә үлми. 1922 елда, ач-ялангач булуына карамастан, халык акча җыеп, Мәскәүдән рөхсәт алып кайта һәм мәчетне яңабаштан төзергә керешә.

Ленин үлгән елны бу төзелешне тагын тукталар. Халык җыелып, үз вәкилләрен тагын Мәскәүгә, Сталинның үзенә җибәрә. Ни гаҗәп, Сталин аларга рөхсәт бирә. Бу вакытта илдә инде дини үзәкләргә коммунистларның канлы кулы тыгыла башлый, чиркәү-мәчетләр ябыла, ә монда... Кабан күле буендагы тыныч бер култыкта, шәрекъ чигешләрен файдаланып, модерн стилендә зифа манаралы мәчет – соклангыч таш поэма төзелеп ята. Гаҗәп бит!

1926 елда анда бик күп халык җыелып, гомуми намаз укый. Беренче һәм соңгы тапкыр... НКВД хезмәткәрләре мәчетне яптыралар һәм аен бәреп төшерәләр. Гөмбәздәге ярадан шул еллардан бирле эчкә яңгыр суы агып тора.

Әгәр бу мәчет телгә килсә, ниләр сөйләмәс иде. Сугыш вакытында аның манарасына зенит пулемёты куела, Сталинград ягыннан “адашып” килеп чыккан немец самолётларына шуннан атып яталар.” (Галиев М.Б. Ташларда да кеше язмышлары... // М.Б.Галиев. Талисман: публицистик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 454 б.)

Бөек мәгърифәтче-галим, күренекле әдип, атаклы мөфти, гадел казый Ризаеддин Фәхреддинне 1922 елда Мәскәү Кремлендә милләтләр халык комиссары И.В.Сталин кабул итә. Мөфти хәзрәт Россиядә (дөресрәге, Идел буе Болгарстанында) Исламны рәсми кабул итүгә 1000 ел тулу уңаеннан аңардан Казанда мәчет салу өчен рөхсәт сорый. Сталин ризалык бирә. Озакламый 1926 елда рухи мәркәзебездә зур дини тантана була – Кабан арты мәчете ачыла.

(...Туксанынчы еллар башында Кабан арты мәчетенең яңадан аякка басуында, торгызылуында, халкыбызга кире кайтарылуында Татарстан Хөкүмәтенең, Исхак хәзрәт Лотфуллинның өлеше гаять зур булды. Без, студент чакта, шул мәчеттә берничә тапкыр намаз укыганымны, ифтар мәҗлесенә барганымны хәтерлим әле. Исхак хәзрәтнең җитез хәрәкәтләрен күреп, кыю сөйләшүен ишетеп сокланган идем. Ул чакта аның уң кулы саналган мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһашин белән дә беренче тапкыр шунда таныштырды хөрмәтле җизнәм Илдар Заһидуллин.)

Уфада Декния Нәзарәтенең архивын туплау һәм мөселман мәхәлләләреннән метрика китапларын җыю Сталин терроры елларында Р.Фәхреддиннең зур батырлыгы иде, чөнки хәзер бу архив документлары һәр татар кешесенә диярлек үзенең нәсел шәҗәрәсен – җиде буынын белергә ярдәм итә.

Чын мөселман һәм дин галиме буларак, Р.Фәхреддин “халык исламы”н, ягъни мәҗүсилек – күпаллалык – чоры калдыкларын каты тәнкыйтьләгән һәм изгеләргә, изгеләр чишмәләренә, тау хуҗаларына табынуга каршы чыккан, һәм, берсүзсез, дөрес эшләгән, дип саныйбыз. Уйлап карасак, бүгенге бозыклыкка каршы Р.Фәхреддинчә көрәшергә кирәк. Хәзер татарларның күпчелеге күрәзәчелеккә табына, им-томнарга, күрәзәчеләргә табибларга караганда да күбрәк ышана, әмма Аллаһы Тәгаләгә иман китерми, намаз укымый, ураза тотмый, Ислам динен, фәлсәфәсен өйрәнми. Демократия, гражданлык җәмгыяте төзибез дип кычкырып йөреп, без соңгы егерме елда нинди җәмгыятьтә яши башладык соң? Нинди булсак, шундыйга лаек булдык.

Тарихыбызга күз салсак, татарларда җәдидчелек хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе саналучы Р.Фәхреддиннең XIX-XX г. башы татар мәгарифен үзгәртеп кору турындагы фикерләре бүген дә әһәмиятен югалтмады, чөнки Россия Федерациясендә милли мәгариф, гомумән, әле һаман да уңай хәл ителмәгән борчулы мәсьәлә булып кала.

Үзгәртеп коручы (реформатор) Р.Фәхреддин Оренбург Диния Нәзарәтен Россия империясе, самодержавие мәнфәгатьләрен артык яклаганы өчен тәнкыйтьләгән. Ул аны оештыруның өч төп бурычын әйткән:

“1. Көнчыгыштагы Ислам тотучылар тарафыннан Россиягә карата хөрмәт уятырга;

2. Россия җирендә рәсми статусы булмаган галимнәрне танымаска;

3. Идел һәм Җаек (Урал) елгалары буенда Исламны рәсми дингә әйләндерергә һәм бөтен җирдә мәктәпләр, мәдрәсәләр ачарга”.

Күп еллар казый (судья) булып эшләгән Р.Фәхреддин халык мәгарифе өчен мөфтиләр һичнәрсә дә эшләми һәм мөселманнарның белем бирү системасын үзгәртү, яхшырту өчен аларның статусы (мөфтине император билгеләгән. – И.Ф.) мөмкинлек бирми, дигән. Ләкин мондый катлаулы хәлдән чыгу юлы булганмы соң? Р.Фәхреддин туры юлны тапкан – Ислам диненең дөньяда тоткан урынын белергә кирәк, дип әйткән. Аның фикеренчә, Ислам вакытлы (фани) дөньяның да, ахирәтнең дә барлык сорауларына җавап табарга тиеш. Ул дини гыйлем белән беррәттән дөньяви белем алуны да кирәк санаган. Безнең заман олугъ галимнең уй-фикере дөреслеген тагын бер тапкыр раслады. Бүген Казанда дини гыйлем бирә торган Россия Ислам Университеты, атаклы “Мөхәммәдия”, “Ислам динен кабул итүгә 1000 ел” исемендәге югары мөселман мәдрәсәләре эшли. Моннан тыш, башкалабызның Ш.Мәрҗәни исемендәге, “Сөләйман”, “Гадел”, “Рамазан”, Нагорный бистәсенең “Иман нуры” мәчетләре каршында башлангыч мәдрәсәләр ачылды. Ата-бабайларыбызның гасырлар буе тупланган тормыш тәҗрибәсен истә тоту, акыл хәзинәсен үзләштерү, авыр язмышыннан гыйбрәт алу безне алда сагалап торган хаталардан саклап калырга булышачак, милли дәүләтчелегебезне тулысынча тергезүгә булган хыял-омтылышыбызны сүндермәячәк!

Кулаткы укуларының әһәмияте бәхәссез, минемчә. Бирегә бүген 200 имам, 100 абыстай чакырылган. Бу хәтле халыкны бер урынга җыю – үзе зур эш икәнлеген, заманында Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитетында биш ел хезмәт иткән кеше буларак, бик яхшы аңлыйм. Әйе, киңәшле эш таркалмас, дигән сөекле халкыбыз. Шуңа күрә дин әһелләрен татар авылларыннан җыеп, мәхәлләләрне хәзерге вакытта борчыган, көн кадагында торган мөһим мәсьәләләр хакында сөйләшү, уйлану һәм нәтиҗәдә ниндидер бер уртак фикергә килү, килешеп эшләү һәм руханиларга дөрес юнәлеш бирү таләп ителә. Милләтнең көче бердәмлектә! Асылыбызга кайткан чакта көчне бер йодрыкка туплау өчен, уңышка ирешү өчен Эдуард хаҗи кебек җитәкчеләр, лидерлар күбрәк кирәк безнең милләткә, җәмәгать! Безгә милли-дини яктан берләшү җитми, таркаулык хас. Татар төрле милли оешмаларга, мөфтиятләргә бүлгәләнергә ярата. Зирәк халкыбызның акыллы сүзләрен онытабыз бит: “Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар”. Мәсәлән, Сездә, 170 мең татар яшәгән Ульян өлкәсендә, өч Диния Нәзарәте

барлыгын ишетеп гаҗәпкә калдым. Бөтен өлкәгә бер мөфти җитмимени?! Бүгенге укуларга өчесенең берсе дә килмәгән. Тәкәбберлек түгелмени бу күренеш? Яки татарлар күпләп яши торган Свердлов өлкәсендә дә өч мөфтият эшли дигәч, тагын уйга баттым. Нигә шулай? Гыйбрәтле бер мәзәк искә төште: җомга намазына дип күрше татар авылыннан атка утырып ике мулла килгән, ди. Берсе карт, икенчесе яшь мулла икән. Карт мулла мәчет рәшәткәсенә атын бәйләп куйгач, яшенә әйткән:

- Чанадагы печәнне атка сал әле.

- Үзең сал, ат синеке бит, - дип җавап кайтарган яшь мулла.

Аларның тарткалашуын ишеткән мәчет карты әйткән, ди:

- Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?

Халкымның шушы әйтеме бүгенге хәлебезне тасвирлый да бирә. Еш кына халыкның зирәк фикерен нишләптер онызталар... Онытмасак, күп ялгышлардан котылыр идек.

Хөрмәтле имамнар, абыстайлар, асылыбызга кайту юлында Сезнең өлешегез бниһая. Мин Сезне педагогка тиңлим, чөнки Сез көн саен халык белән турыдан-туры аралашасыз, мәхәллә проблемаларын эчтән, мәхәлләнең һәр кешесен якыннан беләсез. Адәм баласын тәрбияләү иң авыр эш булганга күрә, Сездән зур сабырлык сорала, ә сабыр төбе – сары алтын, дип юкка гына әйтмәгән безнең халык. Дини кадрлар мәсьәләсе хакында төптән уйланырга кирәк, ягъни үзегез урынына лаеклы алмаш әзерләүне бүгеннән үк кайгырта башлау өметле, нәтиҗәле булыр. Бу җаваплылык Сезнең өстегездә һәрвакыт торыр.

Бүген Тәлгат Таҗеддиннән, Равил Гайнеддиннән тыш, кайсы өлкә мөфтие илебез президенты В.В.Путинга эләгә ала – аның кабинетына керә ала? Бармы андыйлар? Юк дип беләм. Илбашына мөрәҗәгать итәр өчен рухи яктан да, дөньяви яктан да нык әзерлекле, конкрет тәкъдимле, эш күрсәткән тәҗрибәле рухани булырга кирәк дип уйлыйм. Безнең милләткә хәзерге заманда Галимҗан Баруди, Ризаеддин Фәхреддин кебек атаклы мөфтиләр җитми...

Асылыбызга кайтканда шулай ук татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге урынына игътибар итү сорала. “Җәннәт – әниләрнең аяк астында”, – дип әйткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.). Россия мөслимәләре берлеге рәисе Наилә ханым Җиһаншина, дизайнер Ләйсән ханым Хаҗиева оештырган татар мөслимә хатын-кызлары киемнәре күргәзмәсен карагач, үземне Сөенбикә-ханбикә чорында хис иткәндәй булдым. Халкыбыз әйтмешли, булганнан бар да була: менә ул Ислам модасы, безнең гүзәл затларыбызга Шәригать кушканча, үзебезчә, чын милли күлмәкләр теккәннәр бит. Күргәнебезчә, зур кызыксыну, сораштыру, мактау

күп булды, әлбәттә. Яшәештә дә хәләл җефетләребезне шундый күркәм киемнәрдән күрергә Раббыбыз насыйп итсен.

VIII Кулаткы укуларына килгән барлык имамнарга, абыстайларга һәм чараны оештыручыларга: Ульян өлкәсенең Иске Кулаткы районы муниципаль берәмлеге башлыгы Эдуард Әнвәр улы ГАНИЕВка, Иске Кулаткы районының татар җәмгыяте рәисе Сәерхан Габдулла улы ӘХМӘРОВка, “Ислам динен кабул итүгә 1000 ел” исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт ҖИҺАНШИНга мин ихластан зур рәхмәт әйтәм!

Аллаһ барчабызга да саулык-сәламәтлек бирсен, җәннәт савабын алырга ярдәм итсен, җәһәннәм газабыннан Үзе сакласын, ә җыелышыбызны мөбарәк кылсын. Әмин.

Үәссәләәмүгаләйкүм үә рахмәтуллааһи үә бәракәәтүһ!